**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 30 сентябрендәге 4099 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Мәскәү районындагы**
**җир кишәрлегенә ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 155 кв.м;
- үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:100412:19;
- үзенә карата хокуклар чикләнә торган кадастр кварталы – 16:50:100412;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Мәскәү районы;
- урнаштыру максаты: электр белән тәэмин итүне (технологик тоташтыруны) оештыру өчен;
- билгеләү вакыты: 10 ел;

1.2. гариза бирүчеләр: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү нигезләре: гариза бирүченең мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартларын билгеләү тәртибе турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, электр челтәрләренә технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында 2023 елның 17 августындагы 2023/КЭС/550/Т167 номерлы шартнамә.

2. Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә һәм кадастр кварталының бер өлешеннән файдалану сервитутны гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт 30 календарь көнне тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә расланa дип билгеләргә.

4. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

5. Әлеге карарга 2 номерлы кушымтадан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

7.1. әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлегенең хокук иясе белән ачык сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзергә;


7.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген һәм кадастр кварталының бер өлешен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, алардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта
Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 30 сентябрендәге
4099 номерлы карары белән
расланды

**Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб 1:500
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар (гамәлдәге) |

| | |
|---|---|
|  | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
|  | капиталь төзелеш объектлары |
| 16:50:100412 | кадастр кварталы |
| 16:50:100412:19 | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

____________________________